Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Советы
К А Р А Р Ы

18 декабрь 2017 ел №214

Муниципаль предприятиеләргә, учреждениеләргә (оешмаларга) гражданнарның, оешмаларның исемнәрен, тарихи вакыйгаларны мәңгеләштерү максатыннан аларның исемнәрен бирү, алыштыру тәртибе турында

2003 елның6 октябрендәге“Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принципларытурында”№ 131-ФЗ Федераль Закон, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставы нигезендә, дәүләт, республика, муниципаль район үсеше өчен уңай тәэсир иткән күренекле шәхесләр, оешмалар, тарихи вакыйгаларның исемнәрен мәңгеләштерү максатыннан,

Әлмәт муниципаль районы карар бирә:

1. Муниципаль предприятиеләргә, учреждениеләргә (оешмаларга) гражданнарның, оешмаларның исемнәрен, тарихи вакыйгаларны мәңгеләштерү максатыннан аларның исемнәрен бирү, алыштыру тәртибе турынданигезләмәне расларга (1 нче кушымта).

2. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетына әлеге карарны кабул иткәннән соң ике ай эчендә:

күренекле шәхесләрнең, оешмаларның исемнәрен, тарихи вакыйгаларны мәңгеләштерү максатыннан Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетында әлеге мәсьәләләрне хәл итү буенча комиссия төзергә һәм аның составын расларга;

күренекле шәхесләрнең, оешмаларның исемнәрен, тарихи вакыйгаларны мәңгеләштерү максатыннан Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетында әлеге мәсьәләләрне хәл итү буенча комиссиянең Нигезләмәсен әзерләргә һәм расларга;

күренекле шәхесләрнең, оешмаларның исемнәрен, тарихи вакыйгаларны мәңгеләштерү өчен гариза (ходатайство) формаларын әзерләргә һәм расларга;

3 нче пункт 2018 елның 20 февраленнән гамәлгә керә.

3. Әлмәт муниципаль районы җирле үзидарә органнарына күренекле шәхесләрнең, оешмаларның исемнәрен, тарихи вакыйгаларны мәңгеләштерү максатыннан Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетында әлеге мәсьәләләрне хәл итү комиссиясе белән бергәләп эшләүне оештырырга.

4 нче пункт 2018 елның 20 февраленнән гамәлгә керә.

Әлмәт муниципаль районы составына керүче җирле үзидарәләргә тәкъдим итәргә:

күренекле шәхесләрнең, оешмаларның исемнәрен, тарихи вакыйгаларны мәңгеләштерү максатыннан актлар төзегәндә 1 нче пунктта расланган нигезлә мә гә таянырга;

күренекле шәхесләрнең, оешмаларның исемнәрен, тарихи вакыйгаларны мәңгеләштерү максатыннан, Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетында муниципальара мөнәсәбәтләр оештырырга.

5 нче пункт 2018 елның 20 февраленнән гамәлгә керә.

5. Күренекле шәхесләрнең, оешмаларның исемнәрен, тарихи вакыйгаларны мәңгеләштерү өчен объект сайлаганда юридик затларга, оештыру-хокукый формага бәйле булмаган хәлдә, әлеге карарның 1 нче пунктында расланган Нигезлә мә гә таянырга;

6. Район Башкарма комитетының хокук идарәсенә (Шәйхулова Ф.Х) әлеге карарны "Альметьевский вестник" газетасында бастырырга, "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"на, Әлмәт муниципаль районы сайтына урнаштырырга.

7. Әлеге карар, расланган Нигезлә мә нең 3,4,5 нче пунктларыннан кала, рәсми рәвештә басылган көненнән гамәлгә керә.

8. Расланган Нигезлә мә нең 1,3,4,5 нче пунктлары массакүләм мәгълүмат чараларында рәсми төстә басылып 60 көн узгач гамәлгә керә.

9. Әлмәт муниципаль районы Советы аппаратына әлеге карарны Татарстан Республикасының муниципаль норматив-хокукый актлар регистрына юллауны һәм анда кертүне тәэмин итәргә.

10.Әлеге карарның гамәлгә куелуын контрольдә тотуны район Советының закон, хокук саклау, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенәйөкләргә (И.Р. Баһманов).

Әлмәт муниципаль районы башлыгы А.Р. Хәйруллин

1 нче Кушымта 2018 елның 20 февраленнән гамәлгә керә.

Татарстан Республикасы Әлмәт
муниципаль районы Советының 2017 елның18 декабрендәге
№ 214 карарына1 нче Кушымта

Нигезләмә

Муниципаль предприятиеләргә, учреждениеләргә (оешмаларга) гражданнарның, оешмаларның исемнәрен, тарихи вакыйгаларны мәңгеләштерү максатыннан аларның исемнәрен бирү, алыштыру тәртибе турында

1. Гомуми нигезләмә

1.1. Әлеге нигезләмә Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы җирле үзидарәләре (алга таба – муниципаль берәмлек) тарафыннан барлыкка китерелгән муниципаль предприятиеләргә,учреждениеләргә (оешмаларга) шәхесләрне, оешмаларны, тарихи вакыйгаларны мәңгеләштерү максатыннан исемнәрен бирү, алыштыру тәртипләре, кагыйдәләре (алга таба – муниципаль предприятиеләргә, учреждениеләргә (оешмаларга) исем бирү нигезләмәсе) турында.

1.2. Нигезләмә түбәндәге сорауларны җайга салмый:

гражданлык хокукы таләпләренә туры китереп оештырылган предприятиеләргә исем бирүне (1);

Ватанны саклаганда һәлак булганнарның исемен мәңгеләштерү максатыннан аларны муниципаль предприятиеләргә, учреждениеләргә бирүне (2);

күренекле галимнәрнең исемнәрен мәңгеләштерү максатыннан аларны муниципаль предприятиеләргә, учреждениеләргә бирүне (3);

муниципаль предприятиеләргә, учреждениеләргә күренекле шәхесләрнең, оешмаларның, вакыйгаларның исемнәрен биргәннән соң, ул биналарга мемориаль (истәлек) такта куюны (4);

1.3. Муниципаль предприятиеләргә, учреждениеләргә мәңгеләштерү максатыннан сәяси репрессия корбаннарының исемнәрен бирү мәсьәләләрен хәл иткәндә Россия Федерациясенең 1991 елның 18 октябрендәге №1761-1 “Сәяси репрессия корбаннарын аклау турында» гы Законы нигезләмәләре исәпкә алына.

1.4. Муниципаль предприятиеләргә, учреждениеләргә мәңгеләштерү максатыннан күренекле шәхесләрнең, оешмаларның, тарихи вакыйгаларның исемнәрен биргәндә, дәүләт, республика, муниципаль район яки оешмаларга уңай тәэсир итүен исәпкә алырга.

1.5. Муниципаль предприятиеләргә, учреждениеләргә исемнәр бирелә:

Оешма, тарихи вакыйгалар, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы

үсеше өчен сизелерлек өлеш керткән күренекле дәүләт, сәясәт, җәмәгать эшлеклеләре;

Икътисад (шул исәптән сәнәгый, авыл хуҗалыгы, төзелеш, торак-коммуналь хуҗалыгы һ.б. өлкәләр), сәламәтлек, сәнгать, мәдәният, спорт, мәгариф, социаль яклау, яшь буынны тәрбияләү, муниципаль берәмлектә хәйриячелек белән шөгыльләнгән күренекле шәхесләрнең исемнәре;

үзләренең эшчәнлекләре, казанышлары белән муниципаль берәмлекләргә, авыл җирлекләренә файда китергән шәхесләр;

шушы җирлектә туып һөнәри осталыкка ирешкән, казанышлар яулаган һәм шуның белән муниципаль районның данын еракларга тараткан шәхесләр;

муниципаль берәмлек үсешенә этәргеч биргән тарихи вакыйга;

муниципаль берәмлек үсешенә этәргеч биргән оешма;

1.6. Муниципаль предприятиегә, учреждениегә исем бирү турында карар Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба – карар, башкарма комитет) тарафыннан кабул ителә.

Муниципаль предприятиегә, учреждениегә исем бирүне кире кагу башкарма комитетның күрсәтмәсе нигезендә эшләнә.

1.7. Муниципаль предприятиегә, учреждениегә исем бирү бу хакта гариза биргән инициатор ягыннан финанслана.

1.8. Муниципаль предприятиегә, учреждениегә исем бирү муниципаль берәмлек өчен әһәмиятле чара булып санала. Чара тантаналы төстә, җирле хакимият органнары, киң җәмәгатьчелек катнашында уза, матбугат чараларында яктыртыла.

1.9. Карар кабул ителгәч, муниципаль берәмлек Уставы нигезендә рәсми рәвештә халыкка игълан ителә.

## 2. Муниципаль предприятиегә, учреждениегә исем бирү кагыйдәсе

2.1. Муниципаль предприятиегә, учреждениегә исем бирү хәзерге рус әдәби теле нормаларына нигезләнергә (татар телендә булса - татар әдәби теле нормаларына) тиеш.

2.2. Бер үк исемне берничә муниципаль предприятиегә, учреждениегә бирү тыела.

2.3. Әгәр дә берничә муниципаль предприятиегә, учреждениегә бер үк исем бирелгән булып, алар хуҗалык итүдә кыенлыклар тудырсалар һәм кайбер оешмаларга тарихи исемен кайтару максатыннан исемнәрен алыштырырга мөмкин.

2.4. Атаклы шәхесләрнең исемнәре Нигезләмәнең 1.5. пунктына нисбәтле, вафатыннан соң гына мәңгеләштерелә.

2.5. Муниципаль предприятиегә, учреждениегә атаклы шәхесләрнең исемнәрен биреп мәңгеләштергәндә Нигезләмәнең 1.5. пунктына нисбәтле шәхеснең туганнарының фикере исәпкә алына (5).

2.6. Предприятиегә, учреждениегә атаклы шәхесләрнең исемнәрен биреп

мәңгеләштергәндә объектив булу өчен:

шәхесләр вафатыннан соң 5 ел узган булу шарт;

тарихи вакыйганың узуына 10 ел вакыт кирәк.

Нигезләмәнең беренче һәм икенче абзацлары Советлар Союзы Геройларына, Россия Федерациясе Геройларына,Социалистик Хезмәт Геройларына, Россия Федерациясе Хезмәт Геройларына, Дан ордены,“Ватан алдындагы казанышлары өчен”, “Татарстан Республикасы алдындагы казанышлары өчен” орденнарына лаек булучыларга кагылмый.

2.7. Муниципаль предприятиегә, учреждениегә мәңгеләштерү максатыннан шәхеснең исемен биргәндә туганнары инициатор була алмыйлар.

## 3. Карарларны кабул итү тәртибе

3.1. Муниципаль предприетиягә, учреждениегә исем бирүнең инициаторы дәүләт һәм җирле Үзидарә органнары, хезмәт коллективлары, җәмәгать оешмалары, шулай ук 25 кешедән ким булмаган инициатив төркемнәр (алга таба – инициаторлар) булырга мөмкин. Инициатив төркемдәгеләрнең яртыдан күбрәге шушы муниципаль берәмлекнеке булырга тиеш. Алар арасында Нигезләмәнең 2.7 пунктындагылар булырга тиеш түгел.

3.2. Инициаторлар Башкарма комитетка түбәндәге документларны тапшырырга тиеш:

1)инициатор турында белешмә биргән  гариза яки ходатайство (юридик затлар өчен – юридик затның исеме, юридик адресы, элемтә өчен телефоны; физик зат өчен – исем фамилиясе, атасының исеме, яшәү урыны, паспорт белешмәсе, элемтә өчен телефоны), шәхеснең исемен мәңгеләштерергә кирәклеген дәлилләгән кушымта, чараны финанслау турында тәкъдимнәр.

2) исеме мәңгеләштерелүче зат, оешма яки вакыйга турында архивтан раслаучы документ.

3)исем бирелә торган муниципаль предприятие, учреждение турында мәгълүмат, шулар исәбендә:

исеме, урыны һәм юридик адресы;

җитәкченең исем фамилиясе, контакты;

оешма әлеге дәрәҗәле исемне бирүгә лаек икәнлеккә белешмә.

4)муниципаль предприятие, учреждение җитәкчесенең тәкъдимне кабул итү-итмәве турында ирекле рәвештә язылган фикере;

5) муниципаль предприятие, учреждение учредителенең тәкъдимне кабул итү-итмәве турында ирекле рәвештә язылган фикере.

3.3. Башкарма комитет кергән гаризаларны, материалларны кабул итә, терки, әзерли һәм 5 эш көне эчендә тикшерү өчен Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы комиссиягә тапшыра (алга таба – комиссия).

3.4. Әгәр дә Башкарма комитетка тапшырылган документлар тулы түгел яки тиешле таләпләргә, Нигезләмәнең 3.2. пунктына туры килмәгән очракта ул аларны инициаторга, төзәтеп бирергә дигән тәкъдим белән кире кайтара.

Инициаторлар үз чиратында, кимчелекләрне төзәткәч, гариза язып документларны яңадан тапшыра ала.

Шулай ук, документлар Нигезләмәнең 3.10 пунктындагы икенче абзацка бәйле, инициаторга кире кайтарыла ала.

3.5. Комиссия Башкарма комитет каршында төзелә.

3.5.1.Комиссия составы, аның эшчәнлеген билгеләү Башкарма комитет тарафыннан раслана.

3.5.2. Комиссия составының өчтән бер өлешен җитәкче урыннарда булмаган җәмәгатьчелек вәкилләре, җирле үзидарә органнары вәкилләре тәшкил итәргә тиеш.

3.5.3. Инициаторларга (аларның вәкилләренә) комиссия составында эшләү мөмкинлеге тудырылырга тиеш.

3.5.4. Беренче утырыш, гариза (ходатайство) теркәлеп 10 эш көненнән соңга калмыйча Башкарма комитетта узарга тиеш. Комиссиянең йомгаклау утырышы гариза теркәлеп 25 эш көненнән соңга калмыйча үткәрелә. Йомгаклау карарыКомиссиянең беренче утырышында ук кабул ителергә мөмкин. Йомгаклау карарынкабул итү өчен кворум булырга тиеш.

3.5.5. Кирәк булганда Комиссия шәхеснең туганнары фикерен белү максатыннан яки башка очракларда нигезләмәнең 1.5 пунктына нисбәтле, муниципаль предприятиегә, учреждениегә исем бирүнигезләмәсенең 2.5, 3.5.1 пунктларына бәйле рәвештә өстәмә чаралар билгели.

3.5.6. Муниципаль предприятиегә, учреждениегә исем бирелү аерым җәмәгатьчелек әһәмиятенә ия булганда, Комиссия хакимият башлыгына, хокукый нигездә җәмәгатьчелекнең фикерен өйрәнү турында тәкъдим белән чыга (6).

3.5.7. Документларны караганнан соң Комиссия йомгак ясый, йомгаклау утырышыннан соң 3 эш көненнән соңга калмыйча материалларны Башкарма комитетка тапшыра.

Карар чыгарганда комиссиянең йомгаклары исәпкә алына.

3.6. Комиссия тарафыннан муниципаль предприятиегә, учреждениегә исем бирергә дигән карар кабул ителгән очракта, түбәндәге кушымталар белән башкарма комитетка проект әзерләнә:

аңлатма язуы;

комиссиянең нәтиҗәсе;

комиссия утырышының беркетмә күчермәсе;

нигезләмәнең 3.2 пунктында күрсәтелгән документлар.

3.7. Муниципаль предприятиегә, учреждениегә исем бирү турындагы Комиссия карарыуңай кабул ителгәндә, инициатор тарафыннанкаршылыклар булмаганда, Башкарма комитет аппаратынакушымтасы белән Комиссия карары бирелә.

3.8. Әгәр дә инициатор Комиссия карары белән килешмәсә, Нигезләмәнең 3.6, 3.7 пунктында күрсәтелгән, дәлилләгән документлар белән язма рәвештә (ирекле формада) башкарма комитет исеменә

мөрәҗәгать итә.

3.9. Гариза (ходатайство) теркәлеп 30 календарь көн эчендә Башкарма комитет имзалаган карар чыгара.

Чараны үткәрү турында карар кабул ителсә, Нигезләмәнең 3.5.6 пунктына нисбәтле вакыт чиге 15 календарь көнгә озынайтыла (7).

3.10. Карар кабул ителгән очракта Башкарма комитет 3 эш көне эчендә инициаторга карар нәтиҗәләрен җиткерә.

Шул ук мәсьәлә буенча гариза (ходатайство) белән инициатор башкарма комитетка 5 елдан соң мөрәҗәгать итә ала.

## 4. Муниципаль предприятиегә, учреждениегә исем бирү турында муниципаль хокукый актларны тормышка ашыру. Бәхәс һәм каршылыклы фикерләрне җайга салуны хокукый яктан гамәлгә кую

4.1. Муниципаль предприятиегә, учреждениегә исем бирүдәге чыгымнар Нигезләмәнең 1.7 пунктына нисбәтле муниципаль берәмлек бюджеты, юридик затлар, оешмалар һ.б., закон нигезендә тыелмаган чыганаклардан булырга мөмкин.

4.2. Нигезләмәне гамәлгә ашырганда туган бәхәсләр сөйләшүләр нигезендә яки закон тәртибендә хәл ителә.

(1) Муниципаль предприятиеләргә, учреждениеләргә һәм организацияләргә (оешмаларга) гражданнарның, оешмаларның исемнәрен, тарихи вакыйгаларны мәңгеләштерү максатыннан аларның исемнәрен бирү, алыштыру гражданлык хокуклары нигезендә гамәлгә ашырыла яисә, шул ук нигездә, оештыру-хокукый формаларны, исем-атамасын үзгәртмәгән хәлдә калдырыла.

(2) Күрсәтелгән сораулар Россия Федерациясенең 1993 елның14 гыйнварындагы “Ватанны саклаганда һәлак булганнарның исемнәрен мәңгеләштерү” турындагы № 4292-1Законы нигезендә җайга салына.

(3) Күрсәтелгән сораулар Россия фәннәр академиясе белән,2013 елның 27 сентябрендәге “Россия фәннәр академиясе, дәүләт фәннәр академиясен үзгәртү һәм Россия Федерациясенең аерым хокукый актларына үзгәрешләр кертү турында” №253-ФЗ Федераль Законы 7 маддәсе 2 өлеш 9 пунктына нигезләнеп хәл ителә.

(4) Муниципаль предприятиеләргә, учреждениеләргә күренекле шәхесләрнең, оешмаларның, вакыйгаларның исемнәрен биргәннән соң, ул биналарга мемориаль (истәлек) такта кую мәсьәләләре Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2002 елның 1 апрелендәге“Татарстан Республикасында мемориаль такталарны кую тәртибе Нигезләмәсен раслау турында” №163 карары нигезендә хәл ителә.

(5) Исемен мәңгеләштерүгә лаек булган шәхеснең туганнары фикерен исәпкә алу турында Нигезләмәнең 3.5.5. пункты.

(6) Шул исәптән, 2003 елның 6 октябрендәге“Россия Федерациясенең җирле үзидарә органнарын оештыру турындагы гомуми принциплар турында”гы №131-ФЗ Федераль Законның 31 маддәсе нигезендә гражданнардан сорашулар уздыру.

(7) Гражданнардан сорашулар уздыру юлы белән халыкның фикерен белгәндә һәм чираттан тыш утырыш уздырганда, 2003 елның 6 октябрендәге“Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” №131-ФЗ Федераль Законның 31 маддәсе нигезендә, вакытны 15 көнгә озынайту мөмкинлеге каралган.

Әлмәт муниципаль районы башлыгы А.Р.Хәйруллин